ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, ,
423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

N 4 15.03.2024 ел

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 14 мартындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»гы 2 санлы карарын гамәлдән чыгару хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләренә, татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 ноябрендәге 34 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 сентябрендәге 11 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмәнең 4 пунктының 4.4 пунктчасына ярашлы,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 14 мартындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»гы 2 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әһлиева